КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 20 апрель г.Казань № 467

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә социаль әһәмиятле эшчәнлек алып баручы ветераннар, инвалидлар һәм пенсионерлар иҗтимагый оешмалары чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 29 сентябрь, 923 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә социаль әһәмиятле эшчәнлек алып баручы ветераннар, инвалидлар һәм пенсионерлар иҗтимагый оешмалары чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә социаль әһәмиятле эшчәнлек алып баручы ветераннар, инвалидлар һәм пенсионерлар иҗтимагый оешмалары чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 29 сентябрь, 923 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 28 февраль, 185 нче; 2022 ел, 9 июль, 659 нчы; 2022 ел, 7 декабрь, 1297 нче; 2023 ел, 11 апрель, 447 нче; 2023 ел, 12 октябрь, 1301 нче; 2024 ел, 2 март, 116 нчы; 2024 ел, 20 ноябрь, 1024 нче; 2025 ел,

26 май, 357 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә социаль әһәмиятле эшчәнлек алып баручы ветераннар, инвалидлар һәм пенсионерлар иҗтимагый оешмалары чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре вәкаләтле органга җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

5.5 пунктның беренче абзацында «исәп-хисап яки корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.7 пунктның бишенче абзацында татар текстында «субсидияне ирекле рәвештә кире кайтару» сүзләрен «субсидия акчасын ирекле рәвештә кире кайтару» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта татар текстында «Субсидия» сүзен «Субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

7.4 пунктта «субсидияне кире кайтару» сүзләрен «субсидия акчасын кире кайтару» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин